ИЗГЕ АЙЛАР
Хаҗ аена аяк басабыз
→ 4 БИТ

ВӘГАЗЬ
Калебне дәвалау
→ 6 БИТ

НӘСЫЙХӘТ
Аз булса да, гаими гамәл...
→ 10 БИТ

ҮРНӘК ЗАТЛАР
Рабига Әл-Гәдәвия
→ 12-13 БИТЛӘР



**ИЮНЬ, 2022**
№ 06 (323)

Татарстан мөселманнары Дания нәзарәте басмасы


зөлкагъдә, 1443


# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+

# Хаҗ Әкбәр мөбарәк булсын!



**Хаҗ – ул олуг гыйбадәт, зур мөмкинлек! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кабул булган хаҗның әҗере – җәннәт», – дип әйткән.**

ДӘВАМЫ → 4 НЧЕ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!



Фото: dumrt.ru

# Трассаларда намаз бүлмәләре ачыла

**9 нчы июнь көнне «Ирбис» АЗС территориясендә федераль трассада стационар намаз уку бүлмәләрен ачу буенча «Юлчы намазы» проектын гамәлгә ашыруга рәсми старт бирелде.**

«Юлчы намазы» проекты Рәсәй федераль трассаларында урнашкан «Ирбис» автомобильләргә ягулык салу станцияләре территорияләрендә намаз уку бүлмәләрен урнаштырудан гыйбарәт. Илнең барлыгы 7 төбәгендә: Владимир һәм Түбән Новгород өлкәләре, Чувашия, Мари Эл Республикалары, Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы, шулай ук Пенза өлкәсендә 24 стационар намаз уку урыны ачу ниятләнә.

# СӨЕМБИКӘ ХАН-БИКӘГӘ ҺӘЙКӘЛ АЧЫЛДЫ

**10 нчы июньдә Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә Сөембикәгә һәйкәл ачу тантанасы булды. Һәйкәл РФ мөселманнары Диния нәзарәте башлангычы белән куелды һәм Идел буе Болгарында Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын, Касыйм шәһәренә нигез салынуның 870 еллыгын һәм Касыйм ханлыгына нигез салынуның 570 еллыгын бәйрәм итү кысаларында ачылды.**

Һәйкәлне ачу тантанасына илнең төрле почмакларыннан килгән татар дин әһелләре, җәмәгать, сәясәт, фән һәм мәдәният эшлеклеләре, журналистлар һәм шәһәр халкы килде.

Чара Камил хәзрәт Сәмигуллинның Коръән аятьләрен укуы белән башланып китте. Аннан соң тантанага җыелганнарны РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев һ.б. сәламләде.

Рәсми чыгышлардан соң мәртәбәле кунаклар шәһәр халкы һәм җәмәгатьчелек алдында һәйкәлдән тантаналы рәвештә япманы салдырдылар. Һәйкәл татар халкының иминлеге һәм дәүләттә тынычлык хакына үзен корбан иткән көчле рухлы татар мөселман хатыны-ханбикәсен гәүдәләндерә.

Монумент Ока елгасы ярында Хан мәчете каршында, Шаһгали хан мавзолееннан ерак түгел, Сөембикә исеме белән аталган шәһәр скверында урнаштырылган. Ханбикә Касыймда гомеренең соңгы елларын Шаһгали ханның хатыны буларак үткәрә.

Скульптураны Әлфия Рәхмәтуллина, Вениамин Сидоренко, Андрей Губкодан торган иҗат төркеме ясаган.

Тантаналы чара концерт, күмәкләшеп фотосурәткә төшү һәм аралашу белән дәвам итте.

Касыйм шәһәрендә һәйкәл ачылу алдыннан, мөфтиләр Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Равил хәзрәт Гайнетдин очрашты. Анда шулай ук Татарстан мөфтие урынбасары, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Дамир Мөхетдинов, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Рушан Аббясов катнашты. Очрашуда катнашучылар Идел буе Болгарында Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыру барышы турында фикер алышты.

*Сын XVI гасырда яшәгән һәм Казан ханлыгы белән кечкенә улы исеменнән идарә иткән Казан ханбикәсе Сөембикә хөрмәтенә ачылды.*



Фото: dumrt.ru

# КОРБАН БӘЙРӘМЕН УЗДЫРУ ТӘРТИПЛӘРЕ

**Татарстан мөфтиятенең Казыйлар һәм Голәмәләр шуралары тарафыннан 2022 елда Корбан бәйрәмен һәм гает намазын үткәрү тәртипләре расланды.**

Гарәфә көне итеп 8 нче июль (җомга) көне билгеләнде, Корбан гаетенең беренче көне 9 нчы июльгә (шимбә) туры килә (зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне). Бу көнне Татарстанның 1500 дән артык мәчетендә җәмәгать белән бәйрәм намазлары үтәчәк. Корбан бәйрәме уңаеннан үтә торган гает намазын Татарстанның барлык мәчетләрендә дә кояш чыгып 30 минут узгач уку тәкъдим ителә. (Мисал өчен, 9 нчы июль көнне кояш башкалабыз Казанда 03.11 сәгатьтә, Актанышта 02.51 сәгатьтә, Иске Чүпрәледә 03.24 сәгатьтә чыга. Шуңа кояш чыгу вакытларына игътибарлы булу сорала!). Башкала мәчетләрендә корбан гаете түбәндәге тәртиптә үтәчәк:

- **02.30** – иртәнге намаз;
- **02.35-03.10** – Коръән укылу;
- **03.10-03.40** – гает вәгазе укылу;
- **03.41** – гает намазын уку;
- **03.45** – гарәп телендә хотбә, Коръән укып дога кылу.

Гает намазы укылганнан соң махсус билгеләнгән урыннарда корбан чалу башланачак һәм ул Казан шәһәрендә 11 нче июль 20.23 сәгатькә кадәр (кояш баеганчы) дәвам итәчәк. Корбан нисабы күләме – 32 мең сум.

Гарәфә көнендә (8 нче июльдә) иртәнге намаздан башлап, зөлхиҗҗә аеның 13 нче көнендәге икенде намазын да (12 нче июль) кертеп, егерме өч фарыз намазның һәркайсыннан соң сәлам биргәч, Аллаһы Тәгаләне олылап, Аны данлап, өч мәртәбә: ***«Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү вәллааһү әкбәр. Аллааһү әкбәр вә лилләәһил-хәмд»***, – дип тәкбир әйтү мәҗбүри була (хатын-кызлар тәкбирне эчтән әйтә). Бу – Тәшрикъ көннәре дип атала. Имам вә җәмәгать белән намаз укыганда тәкбирнең вәҗиб булуының мәгънәсе – адәм балалары Җир йөзенә яшәр өчен яратылды, адәм каны коелмасын, хайван каны гына коелсын дип сөенечтән тәкбир әйтүдәдер.

Быел Гарәфә көне җомга көнгә туры килә, димәк, хаҗ кылучылар хаҗиәкбәр исеменә лаек булачаклар. Җомга көненә туры килгәнлектән, хаҗда булмаган кешеләргә пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә ураза тоту киңәш ителә, ул бик савапл гамәл санала.

# КОРБАН БӘЙРӘМЕН ОЕШТЫРУ БУЕНЧА КИҢӘШМӘ

**17 нче июньдә Нәзарәтнең киңәшмәләр залында Казан шәһәренең баш мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин җитәкчелегендә якынлашып килә торган Корбан бәйрәмен оештыру һәм үткәрү мәсьәләләренә багышланган киңәшмә узды. Аның эшендә Казан шәһәре мөхтәсибләре һәм имамнары, ТР Президенты администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитеты һәм бәйрәм вакытында тәртипне тәэмин итү һәм биологик калдыкларны урнаштыру белән шөгыльләнүче вәкилләр катнашты.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Илдар Ногманов киңәшмәдә катнашучыларны йогышлы авырулар таралу буенча имин булмаган җирлекләрдән хайваннарны алып керүдән сак булырга кирәклекне кисәтте; малларны алып кайту Баш ветеринария идарәсе белән килештерелергә тиеш. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, хайваннарның йогышлы авырулары буенча катлаулы хәлләрне исәпкә алып, Татарстан халкын да корбанлыкларны республикабыздан сатып алырга чакыра.

Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы Идрис Гатин закон актлары таләпләрен үтәргә чакырды һәм катнашучыларны мәҗбүри тәртиптә гамәлгә ашырылырга тиешле эшләр исемлеге белән таныштырды. Бу – махсус контейнерларга биокалдыклар җыю, тиреләрне тоз белән эшкәртү, канны һәм каты көнкүреш калдыкларын җыю.

Татарстанда биологик калдыкларны эшкәртү белән «Алабуга» махсус икътисади зонасы территориясендә төзелгән бердәнбер «САРИЯ Био-Индастрис Волга» заводы шөгыльләнә. Бүген «САРИЯ Био-Индастрис Волга» ҖЧҖ проекты җитәкчесе Антон Шишкин биокалдыкларга куела торган таләпләр турында сөйләде. Ә тиреләрне җыю һәм тоз белән эшкәртү буенча «Антика» ҖЧҖ вәкиле Махач Анатов чыгыш ясады.

Шәһәр Башкарма комитетының иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы урынбасары Илгиз Сарманов хәбәр иткәнчә, Корбан бәйрәме Казанда һәм Татарстанда «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» ТР Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 нчы мартыннан кабул ителгән 208 нче номерлы карарны үтәп узарга тиеш. Башкарма комитет вәкиле биокалдыкларны юк итү һәм утильләштерүгә куйган таләпләр инструкция рәвешендә мәчет вәкилләренә таратылды, алар аттестацияләнгән мәйданчыкларны оештырырга планлаштыра. Әлеге мәйданчыкларның әзерлеген махсус комиссия бәяләячәк, аларны якын арада тикшереп чыгачак.

ТР Президенты Администрациясе департаментының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү идарәсенең Дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире Ленар Сәлахов мөхтәсибләрне Корбан бәйрәмен оештыруга һәм үткәрүгә җаваплы карарга чакырды. Ул Корбан гаете халыкта бәйрәм рухы калдырырга тиеш, дип белдерде. Шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетына бу юнәлештә эшне җайга салу өчен рәхмәтен белдерде һәм Татарстан мөфтиятенә корбан чалуга куелган таләпләрне республиканың барлык мөхтәсибәтләренә җиткерүне сорап мөрәҗәгать итте.

**dumrt.ru** сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 06 (323) июнь, 2022 | зөлкагъдә, 1443

# ХАҖ АЕНА АЯК БАСАБЫЗ




Фото: yandex.ru

*Корбан бәйрәмендә корбан чалу – малың белән башкарыла торган вәҗиб гыйбадәт. Моның хакындагы вәхи һиҗрәтнең икенче елында иңдерелгән.*

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ислам дине биш баганага нигезләнә: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга лаеклы Зат юк һәм Мөхәммәд Аның Расүле дип шаһитлык китерү, намаз уку, малдан зәкят бирү, Рамазан аенда ураза тоту һәм мөмкинлеге булган кешегә Кәгъбәтулланы зиярат итеп, хаҗ кылу», – дигән. Бу нигезләр Ислам диненең генә түгел, ә һәр мөселманның терәге булып тора. Һәр мөселман бу терәкләргә ныклап ябышырга, аларны өйрәнергә һәм гамәлгә ашырырга тырышырга тиеш!**

## ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ НИЧӘ ТАПКЫР ХАҖ КЫЛГАН?

Мәсәлән, намазны көн саен укыган, уразаны Рамазан саен тоткан, дип әйтеп була. Ә хаҗга килгәндә, ул ничек булган икән? Пәйгамбәребез Мөхәммәд бер тапкыр хаҗ кылган, һәм безгә дә хаҗ кылу рәвешен өйрәтеп калдырган. Чыннан да, хаҗ гыйбадәте нинди генә олуг булмасын, кеше үз гомерендә бер тапкыр хаҗ кылса, өстеннән фарызны төшергән була. Әйткәнебезчә, фарыз булса да, Пәйгамбәребез хәдисләрендә хаҗ турында әйткәндә: «Булдыра алганнар өчен», – дип әйтә иде. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

*«Һичшиксез, кешеләр [гыйбадәт кылсын] өчен корылган тәүге йорт – мөбарәк һәм [кыйблалары булу белән] галәмнәр өчен һидаять булган Мәккәдә [Кәгъбәдә]. Анда [беркемдә дә буталчык тудырмый торган] ап-ачык аятьләр [вә галәмәтләр] һәм Ибраһимның мәкамы бар. Кем дә кем анда керсә, [курыкканнарыннан] имин булыр. Юл үтеп аңа [җитәргә] көч тапкан кешеләр Аллаһы өчен [Әл-Харам мәчете булган] Бәйткә хаҗ кылырга тиеш. Кем дә кем [хаҗның фарызлыгын инкяр итеп] кяфер булса, һичшиксез, Аллаһы – [һичнинди гыйбадәткә һәм һичкемгә ихтыяҗы булмаган] бөтен галәмнәрдән бай [Зат]».*

*«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:96-97*

## ХАҖ КЕМНӘРГӘ ТИЕШЛЕ?

«Гыйбадәте Исламия» китабында Әхмәдһади Максуди хәзрәтләре болай дип яза: «Ислам динендә балигъ һәм акылы булган мөэмин кешегә фарыз булган олуг гыйбадәтләрнең бишенчесе – гомерендә бер мәртәбә Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә барып, хаҗ гамәлен кылу.

Сәламәт булып, Мәккәи Мөкәррәмәгә барып кайтырлык мөмкинлеге һәм үзе кайтканчы өендә калган гаиләсенә җитәрлек малы булган бай кешегә генә хаҗ гыйбадәте фарыз. Ире яки мәхрам кардәше белән бергә барса, бай һәм сәламәт хатыннарга да хаҗ фарыз була. Авыру, сукыр һәм фәкыйрь кешеләргә хаҗ гамәле фарыз түгел. Әгәр мондый кешеләр Мәккәи Мөкәррәмәгә ниндидер сәбәп белән барсалар яки Мәккә якларында тору сәбәпле хаҗ кылырга көчләре җитәрлек булса, аларга да хаҗ гамәле фарыз була. Хаҗ сәфәренә чыкканда, барыр юлларының урлаучы-талаучылардан, төрле йогышлы авырулардан имин булуы шарт».

## МӨМКИНЛЕК БАР, ТЕЛӘК КИРӘК

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләр күпме юл үткән. Күбесенең атланып йөрергә дөяләре дә булмаган. Бүгенге көндә, Аллаһыга шөкер, автобуслар, самолетлар бар. Эссе кояш астында тормас өчен палаткалар да, кояштан саклый торган җиһазлар да, кондиционерлар да ул вакытта булмаган. Әмма риваятьләрдә Пәйгамбәребез белән бергә 114 меңгә якын кеше хаҗ кылган дип килә. Күпме кеше аның белән хаҗ кылу бәхетенә ирешә, аның хаҗ кылу рәвешен өйрәнеп калды, хотбәсен тыңлады... Бер тапкыр кылабыз, тәнем зәгыйфь, малым әле аз дип гафиллектә яшәмик: хаҗ турында гыйлемнәребезне бүгеннән арттыра башлыйк. Берәр көнне хаҗ кылырга мөмкинлек чыккач, югалып калырга мөмкинбез. Хаҗ – ул беренчедән, олуг гыйбадәт, икенчедән– мөмкинлек! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кабул булган хаҗның әҗере – җәннәт», – дип әйтте. Шулай ук хәдисләрдә Гарәфә көнне Раббыбызның бик күп мөслим-мөслимәләрне ут газабыннан азат итүе турында әйтелә. Ул үзе дә Гарәфәдә өммәте өчен нинди зур дога кылды бит! Пәйгамбәребез беркайчан да үзе турында гына уйламады, ә: «Өммәтем, өммәтем», – диде. Бу хәдисләрдән хаҗның, чыннан да, зур мөмкинлек икәнен күреп була. Шуңа күрә, бер тапкыр гына кыласы да, бетте инде, дип уйларга ярамый. Аңа чын күңелдән әзерләнеп: «Башка бара алмаска мөмкинмен. Бу соңгы хаҗым булырга мөмкин, Раббым, кабул була торган хаҗлардан кыл», – дип, догалар кылсак иде. Онытмыйк, кабул булган хаҗ безнең гөнаһларыбызның ярлыкануына сәбәп була, безгә җәннәт бүләк итә! Пәйгамбәребез: «Кем дә кем начар сүзләр сөйләшмичә, начар гамәлләр кылмыйча һәм Аллаһыга тулы буйсыну белән хаҗ кылса, ул әле генә туган сабый кебек гөнаһсыз булыр», – дип әйтә. Аллаһы Тәгалә һәр гыйбадәтләребезне бары тик Аның өчен генә, Аның ризалыгын алырга дип кылуны насыйп әйләсен, һәм безне шушы җомга намазларында җыйган кебек, югары җәннәтләрдә дә бергә җыйса иде.

**Шамил Әхмәтгалиев,**
Хәсәншәех авылы

МӨФТИ КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИННЫҢ МӘКАЛӘЛӘР ЦИКЛЫ

## «ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАСЫ»

ДИП АТАЛГАН ЯЗМАЛАР СЕРИЯСЕ



Фото: dumrt.ru

# АСИЯ БИНТЕ МӨЗӘҺИМ

*Дәвамы. Башы алдагы санда.*

### ХӘЗРӘТИ АСИЯНЕҢ ИМАН КИТЕРҮЕ

Балигълык яшенә җиткәч, Муса галәйһиссәлам Мәдьянга күчеп китә һәм анда ун ел яши. Мисырга ул пәйгамбәр сыйфатында кайта һәм Фиргавен янына килеп, аны дингә өнди башлый, таягын еланга әверелдерү могҗизасын күрсәтә. Шуларны үз күзләре белән күргән хәзрәти Асия акылы белән дә, йөрәге белән дә Аллаһыга иман китерә һәм пәйгамбәрнең динен кабул итә.

Аллаһының рәхмәте белән, хакыйкатьне күргән һәм Муса галәйһиссәлам белән көрәштә җиңелгән Фиргавеннең сихерчеләре дә хәзрәти Асия белән бергә иман китерә. Әмма ачыктан-ачык шуны белдергәннәре өчен, аларны газаплап үтерәләр.

Фиргавен сараенда шулай ук Мәшитә исемле бер хатын-кыз яшәгән була, ул да яшерен рәвештә иман китерә. Асия белән Мәшитә бер-берсен дус-сердәш һәм таяныч итеп күрәләр. Аллаһыга гыйбадәт кыла башлавын белгәч, Фиргавен Мәшитәне дә каты җәзага тарта. Әмма бу хатын-кызның иманы нык була, ул Фиргавенгә сәҗдә кылмый, һәм Фиргавен аны үтерергә әмер бирә.

Асия дус кызының үтерелүен йөрәгенә якын алып, кайгыны бик авыр кичерә, аның күңеле хәсрәткә бата, ул дустының эзәрлекләнүен, газаплануын исеннән чыгара алмый. Кечкенә улының әнисе Мәшитәгә әйткән сүзләре калебендә ук булып кадала: «Әнием! Син барысыннан да мәхрүм калдың, хәзер гомерең дә өзеләчәк. Ләкин иманыңны җуйма! Җәннәт бик тә якын!»

Мәшитәнең, аннары сихерчеләрнең җәзалап үтерелүе Асияне Фиргавеннән һәм аның даирәсеннән ерагайта. Аның күз алдына еш кына Мәшитәнең һәм сихерчеләрнең соңгы мизгелләрендәге бәхетле йөзләре килеп баса. Бу хәлләрдән соң ул да, үзенең дин кардәшләре белән җәннәткә эләгергә теләп, газаплы үлем турында хыяллана башлый. Аны инде әйләнә-тирәдәге зиннәт тә, сарай да кызыксындырмый. Хакимият таҗы урынына да ул хәзер иман таҗын киеп йөри. Диннең тәмен тойгач, Фиргавен сараеның киң һәм бай диварлары аның өчен төрмә рәшәткәләренә әйләнә... Вакытының күп өлешен ул үз бүлмәсендә Аллаһыга гыйбадәт кылуга багышлый һәм мөмкин булганча, Фиргавеннән ераклашырга тырыша.

### ГАЗАПЛАНГАН, ӘММА БӘХЕТЛЕ ХӘЗРӘТИ АСИЯ

Хатыны ягыннан салкынлыкны Фиргавен, әлбәттә, сизми калмый. Тик хәзрәти Асиягә карата чиксез мәхәббәте аны хатыны белән йомшак мөгамәләдә булырга этәрә.

Әмма Муса галәйһиссәламнең дине һәм бер-бер артлы җиңүләре Фиргавен кавеменә зур йогынты ясый. Тормышларына куркыныч янауга карамастан, мөселманнар саны арта. Хәзрәти Асиянең дә Фиргавеннең илаһилыгын танымавы аның дәрәҗәсен халык каршында нык какшата. Һәм ул, хатынын чын күңелдән яратуына да карамастан, хакимлек итүе аннан да кыйммәтрәк булуын аңлый. Шуңа күрә Фиргавен хатынын дүрт кадак белән җиргә кадакларга әмер бирә, аның күкрәгенә зур тегермән ташы салдырып, кызу кояш астында калдыра. Шул рәвешле газаплап, ул хәзрәти Асиядән диннән баш тартуын таләп итә. Әмма бу хатын үлем каршында көчле рухлы булып кала.

Сәлман Фариси радыяллаһу ганһедән тапшырылган риваятьтә болай диелә: «Асия бу җәзаларга дучар булганда, фәрештәләр аны үзләренең канатлары белән кояшның кызуыннан каплаган. Шул мизгелдә ул үзенең җәннәттәге йортын күреп алган». Димәк, ул җәннәттәге урынын исән чагында ук күрә икән. Икенче бер риваятьтә болай диелә: «Фиргавен аңа диненнән баш тартырга тәкъдим иткәч, ул аңа болай ди: «Синең шәфкатьсезлегең һәм явызлыгың минем тәнемне авырттыра. Ләкин минем йөрәгем – Аллаһы Тәгалә яклавында. Хәтта син мине вак кисәкләргә бүлгәләсәң дә, мин үз динемнән баш тартмаячакмын».

Хәлсезләнгән Асия янына Муса галәйһиссәлам дә килә. Хәзрәти Асия: «Муса, Раббым миннән канәгатьме, әллә миңа ачулымы?» – дип сорый. Муса галәйһиссәлам аңа: «Асия, Аллаһы сине данлый! Күк әһелләренең барысы да сиңа төбәлгән. Ни генә теләсәң дә, һичшиксез, чынга ашачак», – ди. Һәм шунда йөзен күккә күтәреп, хәзрәти Асия болай ди:

*«Ий Раббым! Җәннәттәге хозурыңда минем өчен бер өй сал! Мине фиргавеннән һәм аның [кәферлегеннән, Синнән башкага гыйбадәт кылу һәм кешеләрне гаепсез хәлдә җәзалау кебек] гамәленнән коткар! Залим кешеләрдән дә мине коткар!»*

*«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:11*

Риваятьләрдә: «Җәннәттәге урыны аңа кәшеф (интуитив тоемлау) юлы белән күрсәтелә, җаны чыкканда ул бернинди дә авырту, газап тоймый. Ә аның өстенә салынган таш җансыз гәүдәдән шуып төшә», – диелә.

Күрегез әле: Асия нинди күркәм дога кыла. Ул фани дөньядагы йорт турында түгел, ә Аллаһыдан җәннәттәге сарай хакында үтенеп сорый. Һәм дөнья байлыгына түгел, ә мәңгелек тормыш ләззәтләренә омтылырга кирәк булуын раслый. Күпләребез өчен нинди файдалы сабак бу!

# КАЛЕБНЕ ДӘВАЛАУ

**Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә калебнең берничә халәте барлыгы хакында хәбәр итә: итагатьле калеб, курка торган калеб, гафләттәге калеб, мөһер сугылган калеб, Аллаһыны зикер кылудан ерак булган калеб, дөнья тормышын ярата торган калеб, үзенең хуҗасына начарлык кылырга әмер бирә торган һәм башка төрле калебләр бар.**

Тышкы яктан без барыбыз да бертөрле күренергә мөмкин, әмма безнең калебләребез төрле. Болар хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

*«...Ләкин бәгырьләре катты һәм алар кылган [начар] нәрсәне шәйтан аларга бизәде».*

*«Әл-Әнгам / Терлек», 6:43*

Галимнәр бу дөньяда иң каты була алган әйберне атаган – ул иман китермәгән кешенең йөрәге. Кешенең калебе катыланса, аннан мәрхәмәт китә һәм кеше каты бәгырьлегә әйләнә. Шуңа да кеше үзенең калебенә игътибарлы булырга тиеш. Ә бер Аллаһыны таныган, Раббысын яраткан, яшәвенең нигезен бер илаһлыкка корган калеб – ул керсез, пакь булып санала.

Бер уйлап карасак, барлык гамәлләребез дә күңелдә башкарыла: күңел белән яратабыз, якын итәбез, мәрхәмәтлелек кылабыз яки башка гамәлләр эшлибез. Әгәр шул йөрәгебез бозылса, башка эш-гамәлләребез дә бозылачак. Шунысын белеп торыйк: бу дөньяда була алган иң авыр җәза – ул калебнең катылыгы. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кеше дучар була алган иң зур җәза – ул калебнең катылануы. Бу кеше өчен иң зур җәза булып тора да инде», – дип әйткән.

Расүлебез соралгач, бер хәдисендә: «Дөреслектә, тимер тутыккан кебек, калебләр дә тутыга», – дип әйткән. Аннан: «Йә, Аллаһының Расүле, ә аны нәрсә чистарта?» – дип сораганнар. Ул: «Үлемне еш искә алу һәм Коръән уку», – дип җавап биргән. Тагын бер хәдистә: «Җеназа намазында еш катнашу», – дип әйткән. Хәтта диннән ерак булган кешеләр дә, җеназаны күреп, үзгәрәләр, дөнья тормышы турында уйланалар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ләззәтләрне җимерә торган үлемне еш искә алыгыз», – дигән. Шуңа күрә һәрбер мөселман кешесенә, калебен чистартыр өчен, айга бер тапкыр булса да зиратка бару мөстәхәб гамәл булып санала. Анда күмелгән төрле яшьтәге кешеләргә карап гыйбрәт алырга тиешбез, чөнки үлем кешенең яшен сорап тормый. Болар хакында уйлану, каберләрне зиярат кылу – иң зур вәгазьче.

## ЕШ ЕЛЫЙБЫЗМЫ?

Кызганычка, Коръән укыганда, калебләребез каты булганга күрә, без еламыйбыз. Аллаһы Тәгалә итагатьле хәлдәге калебнең халәте турында Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

*«Шуннан соң [сөенеч һәм рәхмәт аятьләрен ишетүгә] тиреләре һәм күңелләре Аллаһының зикеренә йомшара».*

*«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:23*

Калебләребез чистарган очракта без Коръән укылышын да, нәсыйхәтләрне дә бөтенләй башка төрле кабул итәбез, Аллаһыны искә төшерсәк, күзләребезгә яшь килә, Аның сүзләре, Коръәндәге аятьләр хакында уйлана башлыйбыз. Калебнең дәваланганын күрсәтә торган билгеләрнең берсе – ул күз яшьләре. Бер тәкъва иясеннән болар хакында соралгач, бердәнбер дәлил – ул Коръән укыганда, нәрсәне дә булса искә төшергәндә калеб чисталыгыннан, йомшаклыгыннан килгән күз яшьләре, дип әйткән. Ә гөнаһлар һәм гафиллек безне Аллаһыдан ерагайта. Пәйгамбәребез, гөнаһ кылган саен йөрәгебездә тап хасил була һәм гөнаһ кылуда даимчылык күрсәтсәк, ул таплар арта һәм калебне тулысынча каплап ала, дигән.

Аллаһыны тыңлый, Аның каршындагы вазифаларын үти башлагач кешенең калебе чистара.

## ДИНИ ВАЗИФАЛАР ҮТӘЛӘМЕ?

Кешенең калебе катылануының тагын бер сәбәбе – дини вазифаларны үтәмәве – бу калебләрне гафиллеккә китерә. Имам Әт-Тирмизи китергән хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Хакыйкатьтә, Аллаһыдан иң ерак булучы кешеләр – ул калебләре каты булучылар». Аннан сәбәбен сораганнар. Пәйгамбәребез: «Алар харам ризыкны күп куллана һәм хәләлдә исраф кыла», – дип әйткән.

Расүлебез болай дип әйткән: «Аллаһы тыйганнан курык – иң хәерле гыйбадәт кылучы булырсың. Аллаһы сиңа биргәнгә риза бул – иң бай кеше булырсың. Азрак көл, хакыйкатьтә, күп көлү калебне үтерә».

Калебнең катылануына китергән өч сәбәп бар. Алар: харам куллану, Аллаһы биргәнгә канәгатьсезлек күрсәтү һәм күп көлү. Берәү дә Расүлебезнең кычкырып көлгәнен ишетмәгән: ул елмая торган булган.

Иң яманы – кешенең калебе катыланганын үзе сизмәве. Мәсәлән, Коръәннең берничә битен генә уку күп вакытны алмый, әмма без моңа вакыт тапмыйбыз. Шул ук вакытта без сәгатебезне бушка үткәрә, бер дә кирәкмәс эшләр белән мәшгуль була алабыз. Бу калебнең каты, гафил булуын белдерә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

*«Алар – иман китергән һәм күңелләре Аллаһыны зикер итү белән [бөтен буталчыклардан, шикшөбһәләрдән котылып] тынычланган кешеләр. Күңелләр Аллаһыны зикер итү белән тынычланмыймы?»*

*«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:28*

Кемдер Пәйгамбәребезгә йөрәгенең каты булуына зарланган. Расүлебез: «Ярлыларны ашат һәм ятимнәрнең башыннан сыйпа», – дип әйткән. Бу кешене йомшарта торган гамәл. Бу гамәл кешенең калебен шөкер итүгә, мәрхәмәтлеккә китерә, чөнки кеше кемнедер ашата, изгелек кыла ала икән – бу зур бәхет.

Галимнәрнең тагын бер киңәше – нәсыйхәтләр бирелә торган мәҗлесләрдә еш булу. Нәкъ менә шундый мәҗлесләрдә ихласлылык турында сөйләнә, булган кимчелекләребез искә алына.

Аллаһыны искә алу, харамнардан тыелу, ятимнәрнең башын сыйпау, кешеләрне ашату, галимнәр белән аралашу, җеназа намазларында катнашу, зиратларда булу – калебләрне төзекләндерә торган чаралар. Без болар хакында һәрвакытта да истә тотарга, һәрдаим калебләребезгә карата игътибарлы булырга тиеш.

**ТР МДНнең Дәгъват бүлеге**



Фото: shutterstock.com

# АЛЛАҺЫНЫ МӘХЛҮКАТЛАРЫНЫҢ СЫЙФАТЛАРЫ БЕЛӘН ТАСВИРЛАРГА ЯРЫЙМЫ?

**?**

**Сорау: Аллаһыны мәхлүкатларының сыйфатлары белән тасвирларга ярыймы? Ни өчен Аллаһы Үзенең мәхлүкъларына охшый алмый?**

**Җавап:** Мәрхәмәтле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Тәгаләне яратылган мәхлүкъларны тасвирлаган мәгънәләр белән тасвирларга ярамый, әмма шул ук сүзләр белән тасвирларга мөмкин. Бу хакта имам Әбү Габдулла Әл-Куртуби (671 елларда вафат булган) болай дип язган:

لأن الشيئين لا يشتبهان لاشتباه
أسمائهما في اللفظ وإنما يشتبهان
بأنفسهما أو بمعان مشتبهة فيهما

*«Ике әйбер бер-берсенә атамалары охшаш булу аркасында түгел, ә үзләреннән-үзләре яки үзләрендәге мәгънәләр аркасында охшаган»* («Әл-Әснә фи шәрх әсмәиләһи әл-хүснә вә сыйфәтиһи», 8 б, Мәктәбә Әл-Әсрийя, 2005).

Мәсәлән, кешене дә, Аллаһыны да «белүче» дип атарга була, бу очракта бер үк сүз кулланыла, әмма белемнең асылы һәм мәгънәсе Аллаһы Тәгаләгә һәм кешегә карата төрлечә килә.

Шуңа күрә имам Әбү Җәгъфәр Әт-Тахави (321 елларда вафат булган) үзенең мәшһүр «Гакыйдә»сендә болай дигән:

وَمَنْ وَصَفَ اللَّهَ بِمَعْنًى مِنْ
مَعَانِي الْبَشَرِ فَقَدْ كَفَرَ

*«Һәм кем дә булса Аллаһыны кешеләргә хас булган мәгънәләр белән тасвирласа, шул көферлеккә төшәр»*, ягъни, сүзләр белән түгел, нәкъ менә мәгънәләр белән: Аллаһыга карата мәхлүкъларны тасвирлаган мәгънәләрне кулланырга ярамый.

Имам Гомәр Ән-Нәсафи (537 елларда вафат булган) «Гакаид ән-Нәсафийя»дә болай дип яза:

ليس بعرض، ولا جسم،
ولا جوهر، ولا مصور، ولا
محدود، ولا معدود، ولا
متبعض، ولا متجزئ، ولا
متناه، ولا يوصف بالماهية،
ولا بالكيفية، ولا يتمكن في
مكان، ولا يجري عليه زمان،
ولا يشبهه شيء، ولا يخرج
عن علمه وقدرته شيء

*«[Аллаһы] акциденциягә [гәүдә сыйфаты] дә, гәүдәгә дә, субстанциягә дә ия түгел. Аның кыяфәте юк, Ул чикләнмәгән, күпчелеккә ия түгел, кисәкләрдән тормый һәм кисәкләргә бүленми, беркайчан да бетми. Ул [мәхлүкат] кебек сан һәм сыйфат белән бәйле тасвирламалар белән сурәтләнми, урын биләми, вакыт белән бәйле түгел. Бернәрсә дә Аңа охшаш түгел, һәм Аның белемнәре [күзәтчелегеннән] һәм Аның кодрәте [хакимиятеннән] бернәрсә дә чыкмый»*.

Гакыйдә буенча китапларда әлеге мәгънәләрнең барысын да Аллаһы Тәгаләнең «мүхаләфәтүһу лил-хавәдис» (ягъни «яратылганнардан аермасы» яки «мәхлүкъләр белән охшаш булмау») дигән сыйфатына (атрибутларына) кертәләр.

Әмма рациональ күзлектән караганда да, мантыйк ягыннан, Раббыбызның мәхлүкатлар белән бернинди дә уртаклыгы булмавын дәлилләргә мөмкин. Киләсе дәлилне карап китик:

**1.** Галәмдәге һәр нәрсәнең үзеннән тыш сәбәбе бар (балаларның үз ата-аналарында сәбәпләре бар, детальләрне заводта ясыйлар һәм башкалар);

**2.** Үзеннән тыш сәбәпкә ия булган әйберләрдән торган галәм үзе дә үзеннән тыш сәбәпкә ия булырга тиеш;

**3.** Галәм – энергиягә ия булган, вакыт белән урында бар булган материя. Димәк, галәмнең сәбәбе шушы дүрт категориядән тыш булырга тиеш.

Аллаһыга охшамаганлык шулай ук хәзерге заман фәнни теорияләр белән дә раслана. Танылган инглиз фәлсәфәчесе, гомеренең ахырында атеизмнан баш тартып, Аллаһыга иман китергән Энтони Флю (1923 – 2010) үзенең «Аллаһы бар» дигән китабында, галим Брайан Лефтоу сүзләрен китереп, болай дип яза:

*«Нисбәтлелек теориясе буенча, вакыт белән бәйле булган бар нәрсә дә шулай ук киңлек белән дә бәйле. Бу – бары тик дүрт үлчәмле континуум гына. Аллаһы бу киңлектә туры мәгънәдә була алмый. Әгәр Ул киңлектә юк икән һәм вакытта булган бөтен нәрсә киңлектә дә бар икән, димәк, Ул вакыт эчендә юк»*.

Һәм Аллаһы яхшырак белүчедер.

**Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
ТР МДНе рәисе, мөфти

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 06 (323) июнь, 2022 | зөлкагъдә, 1443

# ӘБҮ ХӘНИФӘ – БАР ЗАМАННЫҢ МӨҖТӘҺИДЕ



Фото: yandex.ru

**Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә гыйлемне иң элек пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аннан соң Пәйгамбәребезнең сәхабәләренә тапшырган. Сәхабәләрдән соң әлеге гыйлемнәр аларга иярүчеләргә – табигыйннәргә күчкән. Табигыйннәрдән Әбү Хәнифә рахимәһуллаһига, ә аннан аның укучыларына күчкән. Теләгән кеше моны кабул итә, теләмәгән, каршы килә ала. Хакыйкать хакыйкать булып кала, моңа карап кына ул үзгәрми (Әбү Бәкер Әхмәд бине Гали Әл-Хатыйб Әл-Багдади – «Тариху Мәдинәти әс-сәлам», Бәйрут, 2001. XV, 460 б).**

### КУФАДАГЫ МӘДӘНИЯТЕНЕҢ КҮПТӨРЛЕЛЕГЕ

Гомәр радыяллаһу ганһе идарә иткән дәвердә Ислам дөньясының географиясе шактый киңәя. Бик күп яңа шәһәрләр төзелә. Шулай итеп, Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң унҗиде ел үткәч, Басра һәм Куфа кебек зур шәһәрләр үсеп чыга. Гомәр радыяллаһу ганһе бигрәк тә Куфаның төзелешенә нык игътибар бирә. Аның әмеренә буйсынып, гарәп телендә иркен аралаша алган кабиләләр шәһәрнең әйләнә-тирәсенә урнашалар. Гомәр радыяллаһу ганһе Габдулла бине Мәсгудны бу шәһәрнең халкына үз белемнәрен тапшырып өчен Куфага җибәрә. Куфа шәһәрендә гыйлемнең таралуына Сәгъд бине Әби Вәккас, Хозәйфә, Гаммәр бине Йәсир, Сәлман Әл-Фариси, Әбү Муса Әл-Әшгарый кебек күренекле сәхабәләр дә үз өлешен кертә. Куфа мөселманнарның мәгариф үзәгенә әйләнә. Куфага килгәч, Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу галимнәрнең күплегенә куанып болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә Ибне Мәсгуд белән булсын. Ул бу шәһәрне гыйлем нуры белән тутырды. Аның укучылары маяк кебек шәһәрне яктырталар» (Әл-Кәүсәри – «Фикһүл-әхлил-Гыйрак вә хәдисәһүм», I, 15 б).

Ибне Мәсгуд радыяллаһу кебек Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу дә гыйлемгә аз игътибар бирмәгән. Ул халыкка динебезнең нигезләрен өйрәткән. Куфа шәһәре Ислам дәүләтенең башкаласы буларак билгеләнгәч һәм галим сәхабәләр Куфа шәһәренә килеп төпләнгәч, галимнәр, мөхәддисләр, Коръән хафизлар һәм гарәп теле белгечләренең саны буенча Куфага тиңнәр булмаган (Әл-Кәүсәри – «Фикһүл-әхлил-Гыйрак вә хәдисәһүм», I, 15-16 б).

Мөхәммәд бине Рабигъ Әл-Җизи һәм Әс-Суютый Мисыр территориясендә яшәгән галимнәр санын исәпләп, бары тик 300 кешене генә билгеләгәннәр. Әл-Иҗли Куфа шәһәрендә генә дә 1500 галим яшәгәнлеген һәм аларның җитмеше Бәдер сугышында катнашканын искә алган (Шунда ук).

Сәхабәләрнең тырышлыклары һәм хезмәтләре бәрабәренә Куфа шәһәре тулы бер университетка әйләнгән. Әнәс бине Сирин ул вакыттагы Куфаны тасвирлап, болай дип әйткән: «Куфага килгәч, мин дүрт мең кешенең хәдисләр өйрәнү белән мәшгуль булуын һәм дүрт йөз кешенең фикһ үзләштерүен күрдем» (Шунда ук. – 20 б. Әл-Кәүсәри – «Мәкаләт», 132 б). Мөгаен шуңа да, Өмәвиләр идарә иткән дәвердә, нәкъ менә мәгарифнең чәчәк атуына бәйле, Куфа шәһәре барлык җәбер-золым күргән мөселманнар өчен сыеныр урыннарына әйләнгәндер.

### ГЫЙЛЕМ АЛУ ЮЛЫНДА

Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Куфада, галим-сәхабәләр тырышлыгы белән бу шәһәр мәдәният һәм мәгариф үзәгенә әверелгәч, һиҗри буенча 80 нче (70) елда дөньяга килгән. Шулай да, ул вакытка инде аның туган шәһәре үзенең әүвәлге йөзен, чисталыгын югалтырга өлгергән. Иҗтимагый-мәдәни яктан Гыйрак Куфа шәһәренә бик җитди йогынты ясаган. Шуңа да Куфа шәһәрендә шигыйлар, хариҗиләр, могътәзилә һәм башка адашкан агымнар таралган. Шуңа да карамастан, сәхабәләрнең укучылары һәм аларга иярүчеләрнең, бигрәк тә, Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе укучыларының тырышлыгы сәбәпле, әһле Сөннәт агымы Гыйрак җирлегендә төп рольне уйнаган. Шул рәвешчә, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Ислам дөньясын фетнә колачлаган дәвердә дөньяга килгән.

Иң элек Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи сәүдә эше белән шөгыльләнгән. Вакыт-вакыт дини җыелышларда һәм түгәрәкләрдә катнашкан. Ләкин алар аның таләпләрен бик аз канәгатьләндергән. Кирәк булганда төрле бәхәсләрдә бик актив катнашкан. Әгәр инде бу фәнни җыелышлар барышында үзара фикер каршылыклары туса, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһига адашкан агымнарның тарафдарлары каршында Әһле Сөннәт карашларын якларга туры килгән. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның әлеге төр бәхәсләрдә уңыш казануы шул дәвернең акыл ияләре тарафыннан да хуплау тапкан. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи кебек атаклы кешенең фәнне читкә куеп, сәүдә белән шөгыльләнүенә алар үз канәгатьсезлекләрен белдергәннәр. Барысы да бертавыштан аны галим булырга, фән белән шөгыльләнергә өндәгән. Шул сәбәпле, Әбү Хәнифә рахимәһуллаһиның гыйлем юлына басуында Имам Әш-Шәгъбинең исемен дә атап үтәргә кирәк. Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи Имам Әш-Шәгъбинең үзенә йогынтысы хакында болай дип искә алган: «Бервакыт, базарга барырга чыкканда, Имам Әш-Шәгъби янынннан үтеп бара идем. Ул мине туктатып, болай дип әйтте:

– Әй, Әбү Хәнифә, көн саен син кем янына барасың?

– Мин базарга барам, – дип җавап бирдем.


– Мин бөтенләй дә ул хакта түгел. Кайсы галимнәрнең дәресләренә йөрисең?

– Даими рәвештә мин беркемнең дә дәресләренә йөрмим, бары тик вакыт-вакыт кына.

– Фәнгә бәйле сорауларны тикшер. Галимнәрнең җыелышларына йөрүгә салкын карама, чөнки мин синдә чагыштыргысыз дәрәҗәдә кызыксыну һәм омтылыш сизәм.

Әш-Шәгъбинең бу сүзләре миңа бик нык тәэсир итте. Шуннан соң мин базарны ташладым һәм фән белән шөгыльләнә башладым». (Әл-Мовәффәк бине Әхмәд Әл-Мәкки, «Мәнәкибү Әбү Хәнифә», «Дарүл-китабел-гарәби» нәшрия-ты, Бәйрут, 1981, I, 54 б).

**Ихсан Шеноджакның «Абу Ханифа – великий муджтахид»** китабыннан тәрҗемә



# ГӨЛБАКЧАГА ӘЙЛӘНГӘН УТ ЯЛКЫНЫ

Фото: shutterstock.com

*(Дәвамы алдагы саннарда)*

**Ибраһим пәйгамбәр халкын потларга табынудан баш тартырга һәм бер илаһлыкка чакыра башлаганнан соң, күпләр аңа иярә, әмма кирелекләре сәбәпле, хакыйкатьтән баш тартучылар да шактый була.**

Әлбәттә, халыкның потларга табынырга каршы булуы Нәмруд патшага бер дә ошамый һәм ул Ибраһим галәйһиссәламнән котылуның юлларын эзли башлый. Залим патша пәйгамбәрне утка ташларга ниятли. Ул кешеләргә, күп итеп утын җыеп, шәһәр үзәгенә алып килергә куша. Нәтиҗәдә тау кадәрле зурлыкта утын җыелып, аңа ут төртелә. Нәмруд патша шул ут ялкынына Нәмруд патшаны ыргытырга әмер бирә. Ул Ибраһим галәйһиссәламнең куркып калуына өметләнә, әмма Раббыбызга тәвәккәл итүе, ихласлыгы көчле булган пәйгамбәр бернидән дә курыкмый һәм хәтта бер мизгелгә генә дә борчуга төшми.

Ибраһим галәйһиссәламнең ныклыгына гаҗәп калган һәм бик нык ачуы чыккан Нәмруд патша ярдәмчеләренә әмер бир: «Аны утка ыргытыгыз!» – ди. Моның шаһиты булган кешеләр тын да алмыйча нәрсә булуын күзәтә. Шул вакытта чын могҗиза була: ут ялкыны гөлбакчага әйләнә. Бу гаҗәеп хәлне күреп, Аллаһыга иман китергән һәм пәйгамбәргә ияргән кешеләрнең йөзләре нур белән балкый, ә Нәмруд патша һәм башка залимнар ачуларыннан бик нык кыза. Күпләр бу хәлне аңлый алмый, үз күзләренә үзләре ышанмый. Әмма Раббыбызның олуглыгын таныган кешеләр, ут ялкынын гөлбакчага әйләндерү Кодрәтле Раббыбызга бернинди дә авырлык тудырмавын аңлый. Коръәндә болай дип әйтелгән:


> *«[Алар аны зур бер ут эченә аткан вакытта] Без: «Ий ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!» – дидек».*
>
> *«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:69*

Бу хәлләрне күзәтеп торган кяферләр моннан соң Ибраһим галәйһиссәламгә зыян салудан баш тарта, Раббыбызның газабыннан курка.

Моннан соң Ибраһим галәйһиссәлам туып-үскән иленнән, Мисырга күчеп китә. Анда аның Исмәгыйль һәм Исхак исемле уллары туа.

Нәни дустым, син Исмәгыйль һәм Исхак галәйһимуссәламнәрнең дә пәйгамбәрләр булганы һәм алар белән дә гаҗәеп могҗизалар башкарылганы хакында пәйгамбәрләр кыйссасыннан укып белә аласың.

Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде


## «Хозур» нәшрият йорты «Хакыйкатьне һәм ялганны аеру өчен гаделлек үлчәүләре» китабын яңадан нәшер итә

**Җәмгыятькә Исламның хакыйкый кыйммәтләрен аңлатуны һәм куркыныч агымнарның һәлакәтле йогынтысыннан кисәтү традицияләрен дәвам итеп, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты, Дагыстан Республикасы мөфтие белән берлектә, «Хакыйкатьне һәм ялганны аеру өчен гаделлек үлчәүләре» («Весы справедливости для различения истины и лжи») китабын чыгарды. Хезмәт авторы – әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать галимнәренең берсе, Сүрия дин белгече Габдел-Кадыйр Гайсә Дийәб.**

Әлеге басмада автор, бары тик хакыйкый чыганакларына нигезләнеп, хәзерге җәмгыятьтә ваһһабчылык идеологиясе тарафдарлары тараткан ялгыш фикерләргә каршы төгәл җаваплар бирә, аларны кире кага. Хезмәттә гакыйдә, фикһ һәм усуль-фикһ, суфичылык һ. б. белән бәйле мәсьәләләр каралган. Китап мөселман динен өйрәнүчеләргә дә, укытучыларга да кызыклы булачак.

**Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.**

- **Кибет: Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6 нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63**
- **Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14 нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09**
- **Интернет-кибет: huzurshop.ru**



Фото: shutterstock.com

# АЗ БУЛСА ДА, ДАИМИ ГАМӘЛ...

*Барыбыз да фазыйләтле «Ясин» сүрәсен белә. Әби-бабайларыбыз Аллаһының рәхмәте белән, «Ясин»нең фазыйләтен, бәрәкәтен тоеп яшәде. Мәрхүмнәр өчен «Ясин» сүрәсен укып, аларга дога кылу да безнең элек-электән килгән күркәм гамәлебез. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ясин – Коръәннең йөрәге. Берәү аны Аллаһы ризалыгы һәм Ахирәттәге иминлеге өчен укыса, Аллаһы аның гөнаһларын ярлыкар», «Ясин»не мәрхүмнәрегез өчен укыгыз», – дигән (Әбү Давыд, Ибне Мәҗе).*

**Телләгебез булса, без һәрнәрсәгә дә вакыт таба алабыз. Игътибар иткәнегез бармы, кайвакытта унбиш минут зикер кылу, Коръән уку шулкадәр озак вакытны ала кебек тоела. Һичшиксез, безнең моңа вакыт җитмәс кебек. «Вакытым күбрәк булганда үтәрмен әле», – дип, бу изге гамәлләрне кылуны кичектерәбез, ә шул ук вакытта ярты сәгатькә, йә аннан да күбрәк вакытка телевизор йә телефонга төбәлеп вакытыбызны «үтергәнне» сизми дә калабыз. Ул ярты сәгать күз ачып йомганчы үтә дә китә. 24 сәгатебезнең заяга узган ярты сәгате бу! Әйе, заяга, чөнки әгәр без ул ярты сәгать эчендә үзебезгә берәр файда алмаган булсак, ул, чыннан да, «җилгә очкан вакыт»...**

Коръән уку вакытның бәрәкәтен бирә, көнебезгә ямь өсти. Кайбер кешеләр вакытлары никадәр генә тыгыз булса да һәркөнне Коръәннең берничә битен яки аның билгеле бер сүрәләрен укырга вакыт таба. Хәтта кыска гына, әмма бихисап зур фазыйләткә ия булган «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен, «Аятел-Көрси»не укуның гына да фазыйләте зур. Моны гадәткә кертергә генә кирәк.

Пәйгамбәребез һәр кичне, йокларга ятар алдыннан, аларны укып, йөзеннән башлап, бөтен тәнен куллары белән сыпырып чыга иде, чөнки бу сүрәләрнең, Аллаһының рәхмәте белән, шәйтаннан саклавын беләбез. «Фатиха» сүрәсенә килгәндә дә, безгә аның шифа сүрәсе икәне мәгълүм. Пәйгамбәребез «Фатиха» сүрәсен, авырулардан шифа, дип атаган.

Гаҗәп! Кыска, әмма фазыйләтле бу сүрәләрне һәрдаим уку, шулар бәрәкәтендә үзебезне дәвалау, саклауда безгә нәрсә комачау итә соң? Бу урында «вакыт җитми», – дип әйтсәк, бу көлкеле җавап булачак!

Ислам тарихында Коръәнне бер төн эчендә дә, бер рәкәгатьтә дә укып чыгучылар булган. Бу кешеләр өчен дә вакыт шул ук 24 сәгать булган, югыйсә. Аларның хезмәте безнекенә караганда күпкә авыррак, катлаулырак иде. Без эшләребез автоматлаштырылган, күпкә җайлаштырылган вакытта яшибез, әмма барыбер вакыт җитмәгәнгә, бернәрсәгә дә өлгерә алмаганга зарланабыз.

Әйе, без бер көн, бер төн эчендә Коръәнне укып чыгу сәләтеннән мәхрүм, әмма бик теләгән очракта һәр көнне даими рәвештә кайбер сүрәләрне уку гадәтен тормышыбызга кертә алабыз. Теләк кенә кирәк!

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Берәү «Ясин» сүрәсен төнлә укыса, иртән гафу ителер», – дигән сүзләрен риваять иткән.

Шул рәвешле һәркем Коръән уку күләмен үзе билгели ала. Кемдер өчен ул көненә 10 бит, берәүләр өчен – 5, ә кайберәүләр өчен бер бит булырга мөмкин. Әмма бер көнне тулы бер җөз, ягъни 20 бит укып куеп, аннары айлар буе Коръәнне кулга да алмау дөрес гамәлме икән? Бәлки аз булса да, әмма даими рәвештә уку Раббыбыз алдында сөеклерәктер?! Бәлки изге гамәлне даими рәвештә кылуыбыз, безгә аның күләмен арттыруда да ярдәм итәр? Пәйгамбәребез: «Аллаһы каршында аз булса да, даими рәвештә кулланылган гамәл сөекле» (имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим), – дип, юкка гына әйтмәгән.

Һәркайсыбыз Коръән укуны күркәм гадәткә кертә, аның бәрәкәтен тормышына күчерә алса иде.

**Айсылу Юлдашева**

# КАЗАННЫҢ ИСЛАМ КИТАПЛАРЫН БАСТЫРУ ҮЗӘГЕНӘ ӘЙЛӘНҮЕ

## КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ МӨСЕЛМАН ТИПОГРАФИЯСЕ БАРЛЫККА КИЛҮ




Фото: wikipedia.org

**Беренче Казан гимназиясе**

**Павел I нең әмере буенча, 1800 елда Санкт-Петербургтан Казанга, гарәп графикасын бастыру өчен, типография җайланмасы кайтартыла. Яңа типография «Азия типографиясе» дигән атама ала.**

Ул беренче Казан гимназиясе каршында урнаша һәм Казан, Ырынбург губернияләре татар-мөселманнарының ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш була.

Типографиянең барлыкка килүендә Габделгазиз Бурашев мөһим роль уйный.

Әле 1797 елда ул император Павел I исеменә Казанда мөселман типографиясе ачу турында мөрәҗәгать юллаган була.



Фото: zavodfoto.mirtesen.ru

Павел I рөхсәт итеп кул куя, әмма бу рөхсәт Сенат тарафыннан кире кагыла. Моннан соң Габделгазиз Бурашев кабаттан мөрәҗәгатен юллый һәм бу гариза 1800 елның 13 нче сентябрендә кабул ителә.

Габделгазиз Бурашев Санкт Петербургтан Казанга җайланманы китертү чыгымнарын да, шулай ук, җайланма Казанга китерелгәннән соң, типография хезмәткәрләренә акча бирүне дә, кәгазь, кара чыгымнарын да үз өстенә ала. Һәм бастырылган һәр мең бит саен биш сум күләмендә салым түли.

Моның урынына ул Коръәнне, догаларны һәм башка мөселман әдәбиятын бастыруга рәсми рөхсәт ала.

Типография җайланмасы 1800 елда Казанга кайтып җитә, әмма бастыруны башлаганчы, Бурашев, Казан губернаторы һәм Сенат җайланманы куллану шартлары хакында рәсми килешүгә килергә тиеш була.

Сөйләшүләр ике елга якын дәвам итә. 1801 елда, Бурашев, әле рәсми рөхсәт булмавына карамастан, мөселман китапларын бастыра башлый.

1801 елда Азия типографиясендә чыккан беренче китаплар – «Һәфтияк» («Коръәни Кәримнең җидедән бер өлеше»), «Аттагоджи» («Иҗекләп уку») китаплары. «Аттагоджи» догалар җыентыгы белән берләшкән татар әлифбасы була.

Алга таба әлеге китап һәр елны диярлек, ә кайвакытларда елына берничә тапкыр «Әлифба иман шартлары белән», «Шарт әл-иман» яки «Иман шарты» исемнәре белән нәшер ителә.

1802 елда, әлифбаны нәшер итүдән тыш, 6 китап: Димәшкътан Мөхәммәд Устуванинең «Устувани китап», Мөхәммәд Пиргулиның «Пиргули», Аллаһияр суфиның «Фәвез әннәҗәт», «Сүбәт әл-гаҗизни» һәм башка китаплар нәшер ителә.

*Дәвамы киләсе санда*

**Дамир Гайнетдинов** язмасы,
islam-today.ru сайтыннан
тәрҗемә

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 06 (323) июнь, 2022 | зөлкагъдә, 1443

# РАБИГА ӘЛ-ГӘДӘВИЯНЕҢ ТӘКЪВАЛЫГЫ



Фото: elements.envato.com

**Без Ислам диненең башлангыч чорларында танылган суфи шәехләр хакында күп ишеттек, алар хакындагы гыйлемнәр бүгенге көнгә кадәр безне гаҗәпкә калдыра. Әмма мондый кешеләр арасында тәкъвалыклары, камиллекләре һәм изге гамәлләр кылулары белән генә түгел, ә кайбер шәехләрдән дә өстенрәк булулары белән аерылып торган хатын-кызлар яшәгәнлеген билгеләп үтми мөмкин түгел. Әлеге бөек хатын-кызларның берсе – Рабига Әл-Гәдәвия.**

## ХӘЗРӘТИ РАБИГАНЫҢ БАЛАЧАГЫ ҺӘМ ЯШЬЛЕГЕ

Хәзрәти Рабига Басра шәһәрендә, ярлы гаиләдә дөньяга килә. Ул дүртенче бала булып туган булуы мәгълүм, шуңа да аңа Рабига исеме бирелгән (сүзгә-сүз тәрҗемәсе – «дүртенче»).

Фәрид Әт-Дин Гаттар аның хакында болай дип язган: «Рабига төнлә дөньяга килде. Аның әти-әнисенең хәтта яктырткычлары да юк иде. Рабиганың әтисе шулхәтле тәкъва кеше иде, хәтта ул берьюлы кешеләрдән бернәрсә дә сорамаска вәгъдә биргән була. Хатыны аңа яктырткыч һәм бераз май бирүләрен сорап, күршеләргә мөрәҗәгать итәргә куша. Әмма ул чыгып китә дә, ишек артында бераз торып, кабат әйләнеп керә һәм хатынына: «Барлык күршеләр дә йоклый, мин сорар кеше тапмадым», – дип әйтә. Шуннан соң ул ятып тора һәм беразга йоклап китә. Рабиганың әтисе төшендә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күрә, ул аңа: «Күңелсезләнмә. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә сиңа игелекле бала җибәрә, ул бөек әүлия булачак, ә аның шәфәгате минем өммәтемнең 70 мең кешесенә насыйп булачак», – дип әйтә. Моннан соң пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа Басраның әмиренә акча сорап мөрәҗәгать итәргә куша. Әмирнең ярлыларга ярдәм итүе – вәгъдәсен бозган өчен кәффарәт була. Бу хатта Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип язарга әмер итә: «Әмирнең исенә төшер: һәр төндә ул миңа – 100, ә җомгага каршы төндә 400 салават әйтә. Бу җомгада ул әлеге гадәтенә салкын карады, шуңа да, моның кәффарәте итеп, сиңа 100 динар бирсен», – ди. Рабиганың әтисе уянгач, үзенең күргән төшен язып куя да, аның хакта әмиргә хәбәр итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзен искә алуына куанган әмир Рабиганың әтисенә 400 динар бирергә куша».

Риваятьләр буенча, әти-әнисенең үлеменнән соң, әле бала вакытында ук, хәзрәти Рабига коллыкка сатып җибәрелгән. Һәм аңа кечкенәдән авыр эштә тир түгәргә туры килгән. Көндез ул ураза тоткан һәм өй эшләрен эшләгән, ә төннәрен берөзлексез гыйбадәттә булган. Берьюлы төнлә уянган хуҗасы аны сәҗдә кылган халәттә күргән, бу вакытта хәзрәти Рабига: «Ий Аллаһым! Син Минем йөрәгемнең бары Сиңа гына омтылганын беләсең. Мин үземне тулысынча Синең әмерләреңә багышларга теләр идем, әмма Синең теләгең белән, мин Синең мәхлукъларыңның берсе булган кешенең кул астында, шуңа да мин Сиңа хезмәт итүдә соңарам, гәрчә бер генә сәгатемне дә юкка үткәрәсем килмәсә дә», – дип, Аллаһыга мөрәҗәгать иткән.

Хуҗа кеше бу хәлгә гаҗәп калган һәм, мондый тәкъва хатын-кызны коллыкта тотарга хакым юк, дип, иртән хәзрәти Рабиганы азат иткән. Моннан соң хәзрәти Рабига зөһедлеккә (аскетлык ред.) бирелеп, тулысынча үзен гыйбадәтләр һәм изге гамәлләр кылуга багышлаган. Ул һәр тәүлек саен меңәр рәкәгать намаз укый торган булган.

Берьюлы аңа Басра хакиме – Мөхәммәд бине Сөләйман Әл-Хашими өйләнергә теләвен белдергән, әмма хәзрәти Рабига: «Сез хәтта барлык байлыкларыгызны миңа тапшырсагыз да, мин бер мизгелгә генә дә Аллаһыдан аерылып, сезгә юнәлә алмыйм», – дип, аның тәкъдимен кире каккан.

## ХӘЗРӘТИ РАБИГАНЫҢ ГЫЙБАДӘТЕ

Хәзрәти Рабига көне-төне гыйбадәттә булган, бары тик кояш чыгар алдыннан гына үзенә бераз ял итеп алуны рөхсәт иткән.

Ибне Әл-Җәүзинең «Сыйфат әссафват» китабында берьюлы хәзрәти Рабиганың хәлен белергә килгән Габдулла бине Гайсәнең сөйләве искә алына, ул: «Мин Рабиганың өенә кергәч, аның йөзе һәрдаим елаганга күрә нур белә балкыганына игътибар иттем», – дигән.

Аның көчле тәкъвалыгы хакында башка китапларда да искә алына. Ул Аллаһыдан оялып, кырык ел буена бер тапкыр да башын да күтәрмәгән.

Рабига Әл-Гәдәвия үзе дә аның вәгазьләренә йөргән, аның замандашы булган Хәсән Әл-Басри, хәзрәти Рабиганың яшәү рәвешен тасвирлаганда, аның өендә бер урыны ватылган су сала торган кувшин гына булуы турында хәбәр иткән. Аның мендәре урынына кирпеч булган, ә гыйбадәтне хәзрәти Рабига салам ише нәрсәдән үрелгән келәмдә кылган. Аның өендә болардан башка берни дә булмаган. Бүләкләр кабул итүдән хәзрәти Рабига баш тарта һәм «Минем дөньяга ихтыяҗым юк», – дип әйтә торган булган.

Хәзрәти Рабига олы яшькә кадәр яшәгән дип риваять ителә. Вафат булу вакыты турында фикер каршылыгы бар: йә ул 135/753, йә 180/796, йә 185/801 елларда бакыйлыкка күчкән.

## ХӘЗРӘТИ РАБИГА ТУРЫНДА РИВАЯТЬЛӘР

Берьюлы аның янына ике олуг шәех килгән. Тамаклары ачыккан бу кешеләрнең Рабиганың өендә аларга бары хәләл ризык кына тәкъдим ителәчәгендә шикләре булмаган. Алар кереп утыргач, хәзрәти Рабига алар каршына ике күмәч куйган, әмма бу вакытта аның ишегенә ике ярлы кеше шакыган һәм хәзрәти Рабига ул күмәчләрнең икесен дә аларга биреп чыгарган. Кунаклар бу хәлгә гаҗәпләнгән, әмма дәшмәүләрен дәвам иткәннәр. Бераздан ишеккә кабат шакыганнар. Хезмәтче кыз унсигез кайнар күмәч салынган кәрзин алып килгән, әмма шәехләрне шаккаттырып, хәзрәти Рабига аңа кәрзинне кире биргән һәм, монда нindидер хата бар, дип, аны чыгарып җибәргән. Күпмедер вакыттан соң хезмәтче кыз яңадан әйләнеп кайткан һәм бу юлы аның кәрзинендә егерме күмәч булган. Хәзрәти Рабига бу күчтәнәчне кабул итеп алган һәм кунакларга тәкъдим иткән. Кунакларның аннан бу гамәле хакында кызыксынуына ул: «Мин шундый мәртәбәле кешеләргә ике күмәч тәкъдим итәргә оялдым һәм шуңа күрә аларны ярлы кешегә биреп: «Йә Аллаһым! Син биргән садакаларыбызны ун тапкыр арттырып кайтаруны вәгъдә кылдың. Мин садака итеп ике күмәч бирдем, миңа ун тапкыр арттырып кайтарсаң иде», – дип дога кылдым. Хезмәтче кыз миңа унсигез күмәч алып килгәч, мин монда хата бар дип уйладым, чөнки мин егерме күмәч алырга тиеш идем. Шуңа да үземнең сораганым китерелгәнгә кадәр, аларны кайтарып бирдем», – дип җавап биргән.

Шул рәвешле Рабига Әл-Гәдәвия гомерен Аллаһыга хезмәт итүгә, гамәл-гыйбадәткә багышлаган тәкъва иясе булып яшәгән.

**Гөлназ Ситдикова**



Фото: elements.envato.com



Фото: shutterstock.com

# Соңгы гыйбадәтем, дип яшәү

**Рабига Әл-Гәдәвия бик тә тәкъвалы хатын-кыз иде. Иртә җиткәч, минем үлем көнем җитте дип, кичкә хәтле гыйбадәттә булган. Төн җиткәч, бу төн үлем төнем дип, иртә җиткәнче гыйбадәттә үткәргән.**
**Ул үлем килгәнче шул халәттә яшәгән.**

**Нәсыйхәт:**


Кеше һәр гыйбадәтен гомерендәге соңгы гыйбадәт дип башкарырга тиеш. Иртән уянгач та, бу көнне үләргә мөмкинлеген уйлап, көнен тиешле дәрәҗәдә үткәрергә тиеш. Нәкъ шул рәвешле төнен дә үткәрергә тиешле. Кич җиткәч, бәлки иртән йокыдан уяныл булмаячакны аңлау кирәк. Әгәр кеше һәрвакытта да боларны истә тотып, тормышын шул рәвешле кора алса, эш-гамәлләре тәртипкә киләчәк.

Әйе, кеше көнен-төнен гыйбадәттә үткәрә алмый. Әмма без һәрбер көн яки төн соңгысы булырга мөмкин икәнлеген истә тотарга сәләтле, чөнки үлем көтмәгәндә килергә мөмкин. Локман галәйһиссәлам улына шундый нәсыйхәт биргән: «Ий минем улым! Тәүбә кылуны иртәгегә калдырма, чөнки үлем көтмәгәндә килергә мөмкин».

***Рабига Әл-Гәдәвия:***
*«һәр гашыйк кеше үзенең сөеклесе белән ялгызы гына калды, ә мин хәзер Синең белән үзем генә. Йә Аллаһым! Әгәр мин Сиңа, җәһәннәмнән куркып хезмәт итсәм, мине анда яндыр. Әгәр мин Сиңа, җәннәткә өметләнеп хезмәт итсәм, мине аннан ку. Әгәр инде мин Синең ризалыгың өчен Сиңа хезмәт итсәм, миннән Үзеңнең мәңгелек күркәмлегеңне яшермә... Аллаһыга карата ярату мине шулхәтле биләп алды ки, минем күңелдә Аннан башканы ярату өчен берни дә калмады. Мин тулысынча Раббым белән кушылдым һәм Аңа бирелдем», – дип әйткән.*

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе: «Кич җиткәч, иртәгә көнгә кадәр, иртә җиткәч, кичкә кадәр яшәрмен, дип уйлама», – дип әйткән.

**«Рухуль Бәйан»**
китабыннын




# *Җиләкле тау сере*

*(Дәвамы. Башы алдагы саннарда)*

Айбикәнең, әйтерсең лә, йөрәгенә җылы дулкын килеп кагылды. Сабырлык белән көтеп алган изге сүзне ишетү бәхетеннән, кырык еллык хезмәт дәверендә җыйналган арулары юкка чыккандай булды.

...Бүген аның хуҗалыкта җаваплы көне. Роботлаштырылган яңа сыер торагы файдалануга тапшырыла. Республикадан һәм районнан килгән җитәкчеләр алдында чыгыш ясыйсын, күпме халык белән очрашасын уйлап, ул тиз генә алма кырды, шуны зәйтүн мае һәм бал белән бутап битенә сылады. Ун минуттан җылымса су белән юып төшергәч, бит урталары алсуланып, тиресе шомарып калды. Хатынын күзәтеп яткан ир:

– Пенсиягә чыккач, бер көн дә эшләмәссең дигән идем...

– Башлаган эшләрем төгәлләнеп килә, җаныем.

Тимерҗан үзе алтмыш яшен түгәрәкләгән көннән бүтән эшкә бармады. Умарталарының күч аерган вакытына туры килүе дә эштән туктарга этәргеч ясады. Тик Айбикә алай булдыра алмады. Илле биш яше, язгы чәчүнең иң кызган вакытында, май аенда тулды. Күңеле төрлесен уйлады: тик шундый җаваплы чорда эштән китәргә намусы җитмәде.

Хәзер йөрәген тыңлый: авыр йөк салынган хуҗалык арбасын тартып барырга көче җитмәвен аңлый. «Зирекле» авыл хуҗалыгы дилбегәсен агроном Вахит кебек тәҗрибәле белгечләр кулына тапшырырга кирәк.

...Айбикәнең күңел күген Хаҗга бару уе гел яктыртып тора. Бар җиһанга нур сибеп торучы Мәдинә шәһәрен, шан-шәрәфле мәгърур Әл-хәрәм мәчетенә аяк басуларын, Кәгъбатулла ташын әйләнеп йөрүләрен төшләрендә күрә...

...Ул көн килде. Казан аэропортында самолет көтеп утырганда, Айбикә Тимерҗанга:

– Карале, безнең каршыга кемнәр килә! Җәмилә белән Рәсүл!

Алар, якын туганнар кебек күрешеп, изге юлда очрашуларына сөенештеләр һәм Аллаһ Тәгаләнең бәндәне тиктомалдан гына очраштырмавына кабат инандылар.

...Самолет, ак болытларны ерып, зәңгәр күккә күтәрелде. Барыр юл озын. Аларның урыннары да янәшә туры килде. Айбикә белән Җәмиләнең сүзләре-сүзгә ялганды. Рәсүл белән гомер итә башлауларына илле ел тулганын әйткәч, Айбикә серле генә елмаеп куйды һәм:

– Бер-береңне вакытыннан алда картайтмыйча яшәү серләре белән уртаклаш әле, дустым, – диде.

Җәмилә, рөхсәт сорагандай, мөлаем карашын иренә сирпеп алды һәм салмак кына тавыш белән сөйли башлады:

Парлы яшәү – бөек сер ул,
Без төшендек шушы сергә.
Бөтенесен тигез бүлдек
Яндык бергә, көйдек бергә.
Гел янәшә бардык җирдә,
Иелә белдек, бөгелә белдек.
Без тәкәббер гөл булмадык,
Бер Ходайга тезләнсәк тә.
Һич беркемнән ким булмадык,
Яндык, ләкин көл булмадык.
Ачу чыкса, ярсу чыкса,
Вакытында тыела белдек,
Дәшмәгәнгә сөенә белдек, – дигәч, шигырьне
Айбикә дәвам итте:
Ярый әйттем! диеп түгел
Әйтмәгәнгә сөенә белдек.
Ялгыш әйтсәк, көенә белдек
Гүзәллекне, матурлыкны
Гомер буе ача белдек.
Бик биеккә менмәсәк тә,
Түбәнлектән кача белдек.
Эшебез белән, сүзебез белән
Бер-беребезне гел зурладык.
Ә тормышта һичбер вакыт
Гадилектән зур булмадык.

– Фәнис абый Яруллинның хатыны Нурсөягә язган шушы шигыре – безнең тормышның девизы булды, диде Җәмилә. – Дөрес язган шагыйрь, парлы яшәү – бөек сер ул! Бер-береңә булган олы мәхәббәт хисен гомер буе саклап яшәү – мәңгелек табышмак!

Айбикә белән Тимерҗанның, әлеге мизгелдә, наз тулы күз карашы очрашты.

...Замананың төрле чорын акыл белән кичергән, мәхәббәтне җилкән итеп, олы тормыш юлы узган дүрт замандаш Изге җиргә аяк басты!

### Гыйлемнең өстенлеге турында төркичә бәетләр

*Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,*
*Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.*
*Белмәде һөнәрне гыйлемсез кеше,*
*Булмады аңарда бәхетнең эзе.*
*Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә,*
*Баш ияләр һәрвакыт белемлегә.*
*Ал гыйлем, чөнки яшәүнең аслы шул,*
*Хәл итә барлык кыенлыкны тик ул.*
*Кем гыйлемле, бел асылташ дип аны,*
*Һич җиңалмас угры яки дошманы.*
*Гыйлемлек – яшьрен хәзинә, кем таба,*
*Ике дөнья байлыгы булыр аңа.*
*Шундый байлык ул – гел өстәп тор аны,*
*Ул, сарыф иткән саен, арта бары.*
*Дөньяның малы кими тоткан саен,*
*Өстәлә белем – сарыф иткән саен.*
*Күп гыйлемле булса адәм – байдыр ул,*
*Башкалар йолдыз кебектер, – айдыр ул.*
*Чын кеше димә туны булганга шәп,*
*Кисә дә атлас, ишәк – һаман ишәк.*
*Тик гыйлем аша табылды тугры юл,*
*Булды гөлбакча ничаклы тозлы чүл.*
*Ит җитәкчең ул гыйлемне син үзең,*
*Шул вакытта дөньяда калыр эзең.*
*Иң элек булды гыйлем, соңыннан – эш,*
*Бик түбән булды гыйлемсез кылган эш.*
*Бәйләсәң эшкә гыйлемне – үлмәссең,*
*Хак юлыннан читкә барып кермәссең.*
*Килсә дә үлем, галим үлми һаман,*
*Үлеме килгәнче үк үлә надан.*
*Бел наданнар төркемен үлек диеп,*
*Үлсә галим, бел аны терек диеп.*
*Син гыйлем тупла, наданлыктан уян,*
*Ахирәт көнне надан – эттән яман.*
*Чын галим үзен надан диеп белер,*
*Күп белим дип, галим артыннан йөрер.*

**Габдрәхим Утыз Имәни**

# «АЗАН» РАДИОСЫ ҖӘДВӘЛЕ (12+)



## ХӨРМӘТЛЕ РАДИОТЫҢЛАУЧЫЛАР!

«Азан» радиосын **azan.fm** сайтында яки **«АЗАН» РАДИОСЫ** рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

**ANDROID ӨЧЕН:** **IPHONE ӨЧЕН:**

| САЙТ: | ВКОНТАКТЕ: | ТЕЛЕГРАМ-КАНАЛ: | ПОЧТА: | ТЕЛЕФОН: |
|---|---|---|---|---|
| azan.fm | azanfm | azanfm | radio@azan.fm | 8 (843) 598-09-43 |

### ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| **0:00** | Коръәни Кәрим 0+ |
| **6:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **6:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **6:30** | Тынычлык тәгълимате 12+ |
| **7:05** | Таян Аллаһка 6+ |
| **7:20** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **7:30** | Иман тәме 12+ |
| **7:50** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **7:55** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **8:05** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **8:30** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **8:50** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **9:00** | Рухи хәзинә 6+ |
| **9:15** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **9:30** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **9:40** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **10:40** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **10:45** | Көндәлек догалар 6+ |
| **10:50** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **11:00** | 40 хәдис 6+ |
| **11:20** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **11:30** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **11:40** | 101 вәгазь 12+ |
| **12:00** | Өйләгә азан 0+ |
| **12:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **12:25** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **12:30** | Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+ |
| **14:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **14:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **14:30** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **14:45** | Сөннәт юлы 12+ |
| **15:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **15:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **15:45** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **16:05** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **16:10** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **16:20** | 101 вәгазь 12+ |
| **16:40** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **17:00** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **17:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **17:30** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **17:40** | 40 хәдис 6+ |
| **19:30** | Әдәбият күрке әдәп 6+ |
| **19:45** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **20:00** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **20:20** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **20:30** | Нәниләргә нәсыйхәт 6+ |
| **20:35** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **20:50** | Көндәлек догалар 6+ |
| **21:10** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **21:30** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **21:50** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **22:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **22:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **22:37** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **22:45** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **23:00** | Коръәни Кәрим 0+ |

### ҖОМГА

| | |
|---|---|
| **0:00** | Коръәни Кәрим 0+ |
| **6:00** | Җомга тәбриге 12+ |
| **6:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **6:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **6:30** | Тынычлык тәгълимате 12+ |
| **7:05** | Таян Аллаһка 6+ |
| **7:20** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **7:30** | Иман тәме 12+ |
| **7:50** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **7:55** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **8:05** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **8:25** | Җомга тәбриге 12+ |
| **8:30** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **8:50** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **9:00** | Рухи хәзинә 6+ |
| **9:15** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **9:30** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **9:40** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **10:00** | Җомга тәбриге 12+ |
| **10:40** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **10:45** | Көндәлек догалар 6+ |
| **10:50** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **11:00** | 40 хәдис 6+ |
| **11:20** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **11:30** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **11:40** | 101 вәгазь 12+ |
| **12:00** | Өйләгә азан 0+ |
| **12:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **12:25** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **12:30** | Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә 12+ |
| **14:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **14:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **14:30** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **14:45** | Сөннәт юлы 12+ |
| **15:00** | Җомга тәбриге 12+ |
| **15:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **15:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **15:45** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **16:05** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **16:10** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **16:20** | 101 вәгазь 12+ |
| **16:40** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **17:00** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **17:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **17:30** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **17:40** | 40 хәдис 6+ |
| **19:30** | Әдәбият күрке әдәп 12+ |
| **19:45** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **20:00** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **20:20** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **20:30** | Нәниләргә нәсыйхәт 6+ |
| **20:35** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **20:50** | Көндәлек догалар 6+ |
| **21:10** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **21:30** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **21:50** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **22:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **22:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **22:37** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **22:45** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **23:00** | Коръәни Кәрим 0+ |

### ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| **0:00** | Коръәни Кәрим 0+ |
| **6:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **6:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **6:30** | Тынычлык тәгълимате 12+ |
| **7:05** | Таян Аллаһка 6+ |
| **7:20** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **7:30** | Иман тәме 12+ |
| **7:50** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **7:55** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **8:05** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **8:30** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **8:50** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **9:00** | Рухи хәзинә 6+ |
| **9:15** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **9:30** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **9:40** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **10:40** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **10:45** | Көндәлек догалар 6+ |
| **10:50** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **11:00** | 40 хәдис 6+ |
| **11:20** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **11:30** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **11:40** | 101 вәгазь 12+ |
| **12:00** | Өйләгә азан 0+ |
| **12:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **12:25** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **12:30** | Кәлам Шәриф. Тәрҗемә 12+ |
| **14:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 6+ |
| **14:10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **14:30** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **14:45** | Сөннәт юлы 12+ |
| **15:05** | Коръән тәфсире 12+ |
| **15:25** | Көндәлек догалар 6+ |
| **15:45** | Бәхет тулы йорт 12+ |
| **16:05** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **16:10** | Гыйбрәтле кыйссалар 6+ |
| **16:20** | 101 вәгазь 12+ |
| **16:40** | Күңелдән күңелгә 12+ |
| **17:00** | Шәхесләргә шәрехләр 6+ |
| **17:10** | Гыйбадәте Исламия 6+ |
| **17:30** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **17:40** | 40 хәдис 6+ |
| **19:30** | Әдәбият күрке әдәп 12+ |
| **19:45** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **20:00** | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) 12+ |
| **20:20** | Һәр яхшы сүз – сәдака 6+ |
| **20:30** | Нәниләргә нәсыйхәт 6+ |
| **20:35** | Пәйгамбәрләр тарихы 12+ |
| **20:50** | Көндәлек догалар 6+ |
| **21:10** | Мәчетләребез тарихы 6+ |
| **21:30** | Әбү Хәнифә (р.г.) 12+ |
| **21:50** | Хәзрәткә сорау 12+ |
| **22:00** | Гыйбадәттә сәгадәт 12+ |
| **22.10** | Әхлак баскычлары 6+ |
| **22:37** | Миллият сүзлеге 6+ |
| **22:45** | Аллаһның 99 исеме 6+ |
| **23:00** | Коръәни Кәрим 0+ |

*** Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый**

## ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррир: **Юлдашева А. И.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2730.
График буенча – 24 нче июнь 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 140, 40 сум.
Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче июнь көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## ИЮЛЬ 2022 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ Сәхәр тәмам | ИРТӘНГЕ НАМАЗ Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Зәвәл | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01 | Җом | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 02 | Шим | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 03 | Якш | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 04 | Дүш | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 11:47 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 |
| 05 | Сиш | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 06 | Чәрш | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 07 | Пәнҗ | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |
| 08 | Җом | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 11:48 | 12:00 | 17:32 | 20:26 | 21:56 |
| 09 | Шим | 01:11 | 01:41 | 03:11 | 11:48 | 12:00 | 17:32 | 20:25 | 21:55 |
| 10 | Якш | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 11:48 | 12:00 | 17:31 | 20:24 | 21:54 |
| 11 | Дүш | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 11:49 | 12:00 | 17:31 | 20:23 | 21:53 |
| 12 | Сиш | 01:15 | 01:45 | 03:15 | 11:49 | 12:00 | 17:30 | 20:22 | 21:52 |
| 13 | Чәрш | 01:16 | 01:46 | 03:16 | 11:49 | 12:00 | 17:30 | 20:21 | 21:51 |
| 14 | Пәнҗ | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 11:49 | 12:00 | 17:29 | 20:19 | 21:49 |
| 15 | Җом | 01:19 | 01:49 | 03:19 | 11:49 | 12:00 | 17:29 | 20:18 | 21:48 |
| 16 | Шим | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 11:49 | 12:00 | 17:28 | 20:17 | 21:47 |
| 17 | Якш | 01:22 | 01:52 | 03:22 | 11:49 | 12:00 | 17:27 | 20:16 | 21:46 |
| 18 | Дүш | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 11:49 | 12:00 | 17:27 | 20:14 | 21:44 |
| 19 | Сиш | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 11:49 | 12:00 | 17:26 | 20:13 | 21:43 |
| 20 | Чәрш | 01:27 | 01:57 | 03:27 | 11:49 | 12:00 | 17:25 | 20:11 | 21:41 |
| 21 | Пәнҗ | 01:28 | 01:58 | 03:28 | 11:49 | 12:00 | 17:24 | 20:10 | 21:40 |
| 22 | Җом | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 11:49 | 12:00 | 17:24 | 20:08 | 21:38 |
| 23 | Шим | 01:31 | 02:01 | 03:31 | 11:50 | 12:00 | 17:23 | 20:06 | 21:36 |
| 24 | Якш | 01:33 | 02:03 | 03:33 | 11:50 | 12:00 | 17:22 | 20:05 | 21:35 |
| 25 | Дүш | 01:35 | 02:05 | 03:35 | 11:50 | 12:00 | 17:21 | 20:03 | 21:33 |
| 26 | Сиш | 01:37 | 02:07 | 03:37 | 11:50 | 12:00 | 17:20 | 20:01 | 21:31 |
| 27 | Чәрш | 01:38 | 02:08 | 03:38 | 11:50 | 12:00 | 17:19 | 20:00 | 21:30 |
| 28 | Пәнҗ | 01:40 | 02:10 | 03:40 | 11:50 | 12:00 | 17:18 | 19:58 | 21:28 |
| 29 | Җом | 01:42 | 02:12 | 03:42 | 11:50 | 12:00 | 17:17 | 19:56 | 21:26 |
| 30 | Шим | 01:44 | 02:14 | 03:44 | 11:49 | 12:00 | 17:16 | 19:54 | 21:24 |
| 31 | Якш | 01:46 | 02:16 | 03:46 | 11:49 | 12:00 | 17:14 | 19:52 | 21:22 |